РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның 4 феврале № 5

**Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 59 номерлы карары белән расланган Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан йөкләмәләрне үтәүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

Түбән Кама шәһәр Советының 2021 елның 18 ноябрендәге 59 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1. Нигезләмәгә 6 нчы кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта).
2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, әмма 2022 елның 1 мартыннан да соңга калмыйча үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының шәһәр инфраструктурасын үстерү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры
вазыйфаларын башкаручы,
Мэр урынбасары М.В. Камелина

Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан йөкләмәләрне үтәүгә муниципаль контроль турында нигезләмәгә
6 нчы кушымта

Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан йөкләмәләрне үтәүгә муниципаль контроль буенча төп күрсәткечләр һәм аларның максатчан кыйммәтләре, индикатив күрсәткечләр

1. Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан йөкләмәләрне үтәүгә муниципаль контроль буенча төп күрсәткечләр

| Төп күрсәткечләр | Максатчан кыйммәтләре (%) |
|---|---|
| Ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозулар арасыннан бетерелгән бозулар өлеше | 70 |
| Контроль чаралар үткәргәндә, тикшерү органы һәм (яки) аның вазыйфаи заты гамәлләренә (гамәл кылмавына) нигезле шикаятьләр өлеше | 0 |
| Контроль чараларның гамәлдән чыгарылган нәтиҗәләре өлеше | 0 |
| Алар нәтиҗәләре буенча бозулар ачыкланган, әмма тиешле административ йогынты чаралары күрелмәгән контроль чаралар өлеше | 5 |

2. Түбән Кама шәһәре территориясендә җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча бердәм җылылык белән тәэмин итү оешмасы тарафыннан йөкләмәләрне үтәүгә муниципаль контроль буенча индикатив күрсәткечләр:

1) хисап чорында үткәрелгән планлы контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

2) хисап чорында үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

3) хисап чорында контроль объектының мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары белән расланган параметрларга туры килү-килмәүне ачыклау яисә контроль объектының мондый параметрлардан читләшүе нигезендә үткәрелгән планнан тыш контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

4) хисап чорында үткәрелгән хезмәттәшлек белән контроль (күзәтчелек) чараларның гомуми саны;

5) хисап чорында үткәрелгән ККЧның һәр төре буенча үзара хезмәттәшлек итү белән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

6) хисап чорында дистанцион хезмәттәшлек чараларын кулланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында игълан ителгән мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында

кисәтүләр саны;

9) хисап чорында аларның нәтиҗәсе буенча мәҗбүри таләпләрне бозу очраклары ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

10) хисап чорында административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында алар буенча прокуратура органнары тарафыннан килештерүдән баш тарткан контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контроль объектларының гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына һәр хәвеф-хәтәр категориясе буенча хәвеф-хәтәр категориясенә кертелгән исәпкә алынган контроль объектлары саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затларның саны;

17) хисап чорында аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралар үткәрелгән исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында аларга карата контроль (күзәтчелек) органы тарафыннан карау срогы бозылган шикаятьләр саны;

19) хисап чорында суд тәртибендә контрольдә тотылучы затлар тарафыннан җибәрелгән контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмавын) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны;

20) хисап чорында алар буенча игълан ителгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән, суд тәртибендә контрольдә тотылучы затлар тарафыннан җибәрелгән контроль (күзәтчелек) органнарының вазыйфаи затларының карарларын, гамәлләрен (гамәл кылмавын) дәгъвалау турында дәгъва гаризалары саны;

21) хисап чорында дәүләт контроле (күзәтчелек) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозу белән үткәрелгән һәм аларның нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралар саны.